ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13 июля 2016 г.**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 1807**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре, Гоголь ур., 39 йорт адресы буенча җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларын алу турында» 21.11.2015 елның 2452 нчы номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча адреслы муниципаль программадан төшереп калдырылуга бәйле рәвештә һәм сүтелергә тиешле Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Гоголь урамындагы 39 нчы номерлы йортны, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 07.07.2016 елның 1751 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 31 декабрендәге 2993 номерлы “Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, күпфатирлы йортларны авария хәлендәге дип тану турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында”, гы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты
**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре, Гоголь ур., 39 йорт адресы буенча җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларын алу турында» 21.11.2015 елның 2452 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:
• күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга;
•МКУ "Зеленодольск муниципаль районының Торак сәясәте департаменты»на;
• торакка хокулы булган милекчеләргә җибәрергә.
3. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н.Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Зеленодольск муниципаль районының

интернет челтәрендә һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштыру юлы белән бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче вакәләтләрен башкаручы А.В. Старостин